# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
Катмыш авыл җирлеге составына керүче Катмыш торак пунктында
2025 елга үзара салым кертү турында

№ 2 31 нче октябрь 2024 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлыФедеральзаконның 25.1, 56 нчыстатьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасызаконының 35 нчестатьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлегенең Катмыш торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге Катмыш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2025 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2.Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәг еэшләрне башкаруга тотарга:
- Катмыш торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Катмыш торак пунктында юлларны вак таш белән каплау (ташу, вак таш салу, эш өчен шартнамә буенча түләү); Катмыш торак пунктында юлларны тигезләү һәм кардан чистарту);
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Катмыш торак пунктында урамнарны яктыртуның энергия саклаучы лампаларын сатып алу, урнаштыру).

3. Әлеге карарны Катмыш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Катмышавылҗирлеге Башлыгы